РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбатавылы, Г.Тукайурамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
04.06.2021

КАРАР
№14

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Юлбат авыл җирлеге Советының
25.02.20021 ел, №6 карары белән расланган
Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә
һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге
җирләргә Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә
яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы прокуратурасының 27.05.20021 нче елгы таләбе нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә кермәгән һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләрдә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 25.02.2002 ел, №6 Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы 25.02.2002 ел, №6 карары белән расланган Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге территориясендә яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.14 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен “рөхсәт ителә» сүзләре белән алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

1.3. «3.8. Авыл башкарма комитеты мөрәҗәгать итүченең хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач өчен түләүне (түләүне) 10 эш көне эчендә авыл җирлеге башкарма комитетының авыл җирлеге

территориясендә яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт бирү турындагы карары проектын әзерли.»;

1.4. Нигезләмәнең 3.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле икенче җөмлә белән тулыландырырга: «киселгән агач өчен бәя (түләү) исәпләү. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.05.2007 ел, №310 карары белән расланган «Урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм Федераль милектә булган урман кишәрлеге мәйданы бирәмлеге өчен түләү ставкалары турында» карары нигезендә исәпләнә.»

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча, җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев